# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Мереткозино авылында 2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

2023 елның 06 декабре №3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Мереткозино авылында гражданнар җыены:

1.2024 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлегенең Кече Мереткозино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучы гаиләләрдән тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (шул исәптән вак таш сатып алу, ташу һәм салу, су агымы торбаларын урнаштыру, юлларны кардан грейдировкалау һәм чистарту);

су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтыки авылы, Бакый Урманче урамы, 9 йорт,
- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мереткозино авылы, Гагарин урамы, 38, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге башлыгы А.Г.Җиһаншин